ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Красновидово авылы
тел. 8 843 77 2 04 13

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Красновидовского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Красновидово
тел. 8 843 77 2 04 13

2018 елның 31 августы № 5

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 24 апрелендәге “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 5 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 24 апрелендәге 5 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.4 пунктына 8, 9 пунктчасыларын өстәргә:

“8) муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт курсәтүен туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.”;

1.2. 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 1-3 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.12. Шикаять карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларга кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Красновидово авылы, Совет ур., 4нче йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Бортас авылы, Үзәк ур., 3нче йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Антон авылы, Колхоз ур., 9а йорт,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Красновидово авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе
урынбасары Н.П. Обидина